# ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

## Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезләмәне раслау хакында

## Шәһәр Советы карары 15.12.2017 №21/13

## Яр Чаллы шәһәре бүләкләре турында Нигезләмә

1. Яр Чаллы шәһәре бүләкләре төзелеш, икътисад, фән, мәдәният, сәнгать һәм мәгариф өлкәсендәге казанышлар, законлылыкны ныгыту, сәламәтлекне һәм тормышны саклау, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау, тәрбия, спортны үстерү, актив хәйрия эшчәнлеге һәм Яр Чаллы шәһәренең үсешенә һәм анда яшәүчеләрнең иминлегенә булышлык итүче башка хезмәтләр өчен бүләкләү формасы булып тора.

2. Яр Чаллы шәһәре бүләкләре (алга таба – шәһәр бүләкләре) булып түбәндәгеләр тора:

1) «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеме;

2) «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» аерымлык билгесе;

3) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Мактау грамотасы;

4) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Рәхмәт хаты;

5) Яр Чаллы шәһәре Хакименең Рәхмәте.

3. Шәһәр бүләкләренә гражданнар, оешмалар, Шәһәр Советы Карарлары нигезендә сайлап куелган һәм билгеләнгән вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр лаек була ала.

4. Шәһәр бүләкләренә тәкъдим ителгәндә бүләкнең төре бүләкләнүченең характеры һәм хезмәт дәрәҗәсе белән билгеләнә. Яңа хезмәтләр өчен шәһәрнең башка бүләге белән бүләкләү алдагы бүләкләүдән соң өч елдан да иртәрәк булырга тиеш түгел.

5. Шәһәрнең шул ук исемдәге бүләкләре белән кабат бүләкләү башкарылмый.

6. Бүләкләү турында тәкъдимнәр барлык милек формалары оешмалары, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре тарафыннан кертелә.

7. Бүләкләүгә тәкъдимнәр шәһәр Хакименә бирелә.

8. Һәр кешегә «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә һәм «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләүгә тәкъдимнәр керткәндә билгеләнгән формадагы Бүләкләү кәгазе (әлеге Нигезләмәгә кушымта) тутырыла, ул бүләкләү турындагы юлламага теркәлә.

9. Шәһәр бүләкләре белән бүләкләнүгә нигезләр һәм шартлар, шул исәптән бүләкләү турындагы юлламага теркәлгән документлар һәм мәгълүматлар исемлеге шәһәр Хакименең хокукый актлары белән билгеләнә.

10. Материалларны җәмәгатьчелек бәяләвен үткәрү һәм бүләкләүгә объектив якын килүне тәэмин итү максатыннан, шәһәр Хакиме тарафыннан «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исемен бирү һәм «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» аерымлык билгесе белән бүләкләү тәкъдимнәрен карау буенча Комиссия (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссиянең эш тәртибе шәһәр Хакиме тарафыннан расланган комиссия турында нигезләмә белән билгеләнә.

11. Шәһәр Хакиме кушуы буенча һәм аның исеменнән шәһәр бүләкләрен тапшырырга мөмкиннәр:

1) Башкарма комитет Җитәкчесе;

2) муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары. Шәһәр Хакиме шәһәр бүләкләрен шулай ук җирле үзидарә органнарының, Яр Чаллы шәһәре муниципаль органнарының башка вазыйфаи затларына тапшырырга хокуклы.

12. Шәһәр бүләкләре һәм аларның документлары, бүләкләнүчеләргә бүләкләү турында шәһәр Хакименең хокукый акты көченә кергән көннән башлап ике айдан да соңга калмыйча, тантаналы шартларда тапшырыла.

13. Әгәр дә бүләкләү үлгән кеше исән чакта каралган булса яки бүләкләү батырлык һәм кыюлык күрсәтү белән бәйле булса, шәһәр бүләкләре белән бүләкләү кеше вафатыннан соң башкарылырга мөмкин. Бүләкнең төрен Яр Чаллы шәһәре Хакиме билгели. Шәһәр бүләкләре һәм аларның документлары үлгәннән соң бүләкләнгән кешеләрнең варисларына саклау өчен бирелә (тапшырыла).

14. Шәһәр бүләге югалган очракта, гариза бирүче мөрәҗәгате буенча бүләкләү фактын раслаучы документның күчермәсе бирелергә мөмкин. Бүләкләү турындагы документ югалган очракта, Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан аның урынына документның күчермәсе бирелә. Бүләкләрнең дубликатлары бирелми.

15. Шәһәр бүләкләре белән бүләкләнүчеләрне исәпкә алу Башкарма комитетның вәкаләтле органы тарафыннан алып барыла. «Яр Чаллы шәһәре каршындагы казанышлары өчен» билгесе белән бүләкләнүче һәм «Яр Чаллы шәһәренең Мактаулы гражданы» исеменә тәкъдим ителгән кешеләргә шәхси делолар ачыла. Шәхси делоларга бүләкләү кәгазе, бүләкләү турында юллама, фотографияләр, бүләкләү өчен бирелә торган башка документлар туплана.

16. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан тармак (функциональ) органнарының Мактау грамоталары һәм Башкарма комитетның территориаль органнарының Рәхмәт хатлары булдырыла.

17. Җирле үзидарә органнары җитәкчеләре Мактау грамоталары, Рәхмәт хатлары, Рәхмәтләр, Дипломнар булдыра ала һәм әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында билгеләнгән бүләкләү төрләрен күздә тота ала. Мондый бүләкләр белән бүләкләү тәртибе һәм шартлары җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокукый актлары белән билгеләнә.

18. Шәһәр бүләкләренә түбәндәге бүләкләү төрләре билгеләнергә мөмкин:

1) кыйммәтле бүләкләр;

2) бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү. Кыйммәтле бүләкләрнең һәм бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең бәясе һәм күләме җирле үзидарәнең финанслау органнары сметалары белән билгеләнә.

19. Мәгариф, сәнгать, спорт, иҗтимагый эшчәнлек өлкәсендә иң талантлы һәм перспективалы балаларны һәм яшьләрне ачыклау, талант һәм хезмәт сөючәнлекне үстерү, сәләтле балаларга һәм яшьләргә матди ярдәм күрсәтү, балалар һәм яшүсмерләр иҗатының барлык төрләрен стимуллаштыру максатларында, шәһәр Хакиме тарафыннан исемле стипендияләр булдырырга мөмкин. Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең һөнәри үсешен стимуллаштыру максатыннан, шәһәр Хакиме премияләрен булдырырга мөмкин. Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү, физик әзерлек, спорт төрләре буенча спорт осталыгы дәрәҗәсен күтәрү максатларында, шәһәр Хакименең күчмә Кубогын булдырырга мөмкин. Исемле стипендияләр, премияләр, кубоклар шәһәр Хакиме тарафыннан Шәһәр Советы билгеләгән күләмдә һәм тәртиптә гамәлгә кертелергә мөмкин.

20. Шәһәр бүләкләре белән бүләкләү турында карарлар, бүләкләү турында карар кабул ителгәннән соң бүләкләүгә тәкъдим итүнең нигезле булмавы яки тәкъдим итүдә күрсәтелгән мәгълүматларның дөрес булмавы ачыкланган очракта, аларны кабул иткән органнар (вазыйфаи затлар) тарафыннан гамәлдән чыгарылырга мөмкин. Бүләкләү турында карарны гамәлдән чыгару бүләкләү турында карар рәсмиләштерелгән кебек үк хокукый акт белән башкарыла.

21. Шәһәр бүләкләре белән бүләкләү турындагы карар гамәлдән чыгарылган очракта, аның атрибутлары һәм бүләкнең таныклыгы Башкарма комитетның вәкаләтле органына кире кайтарылырга тиеш.

22. Әлеге Нигезләмәне гамәлгә ашыру белән бәйле финанс чыгымнары Яр Чаллы шәһәре бюджеты акчалары хисабына башкарыла.